# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Чирмешән муниципаль районының Түбән Чыгтай һәм Чирмешән авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм "Чирмешән муниципаль районы"муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Чирмешән муниципаль районы составына керүче "Түбән Чыгтай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген һәм "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген бу җирлекләр халкының вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Чирмешән авылында булган "Чирмешән авыл җирлеге"нә (алга таба – яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге) берләштерү юлы белән үзгәртеп төзергә.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге беренче чакырылыш вәкиллекле органы һәм башлыгы вәкаләтләре вакытын биш ел дип билгеләргә.
2. Яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органын ун депутат тәшкил итә дип билгеләргә.
3. Яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына сайлаулар билгеләү, сайлауларга әзерләнү һәм аларны үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта башкарыла.

**3 статья**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның

34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан яшерен тавыш бирү юлы белән беренче утырышта сайлап куела.

Яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, аны сайлап кую өчен вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгын сайлап куйганчы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле орган депутатлары арасыннан яшь буенча иң өлкәне ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"**2 статья.** "Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 3 – 21 кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусын бирергә һәм административ үзәкләрен билгеләргә:

Бәркәтә авыл җирлеге: Бәркәтә авылы (административ үзәк);

Югары Кәминкә авыл җирлеге: Югары Кәминкә (административ үзәк), Керкәле, Кызылъяр авыллары;

Ивашкино авыл җирлеге: Ивашкино (административ үзәк), Аккирәй авыллары;

Кармыш авыл җирлеге: Кармыш авылы (административ үзәк), Яшәүче поселогы;

Күтәмә авыл җирлеге: Күтәмә авылы (административ үзәк);

Лашман авыл җирлеге: Лашман (административ үзәк), Әмир авыллары;

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге: Мордва Афонькәсе (административ үзәк), Лагерка, Чуаш Афонькәсе авыллары;

Түбән Кәминкә авыл җирлеге: Түбән Кәминкә (административ үзәк), Кара Чишмә авыллары;

Түбән Кармалка авыл җирлеге: Түбән Кармалка (административ үзәк), Югары Кармалка, Чумач авыллары;

Яңа Әлмәле авыл җирлеге: Яңа Әлмәле (административ үзәк), Иске Әлмәле авыллары;

Яңа Кади авыл җирлеге: Утыз Имән (административ үзәк), Кызыл Чишмә авыллары;

Иске Кади авыл җирлеге: Иске Кади (административ үзәк), Яктытау авыллары, Светлогорский, Тукай поселоклары;

Иске Котыш авыл җирлеге: Иске Котыш (административ үзәк), Красная Поляна, Яңа Котыш авыллары;

Иске Үтәмеш авыл җирлеге: Иске Үтәмеш (административ үзәк), Югары Чыгтай, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино авыллары;

Туймәт авыл җирлеге: Туймәт авылы (административ үзәк);

Ульяновка авыл җирлеге: Ульяновка (административ үзәк), Девичья Поляна, Саминовка, Сосновка авыллары, Нагорный поселогы;

Чирмешән авыл җирлеге: Чирмешән (административ үзәк), Казанка, Түбән Чыгтай авыллары, Кече Чыгтай поселогы;


Шешминка авыл җирлеге: Шешминка (административ үзәк), Андреевка, Павловка авыллары, Нагай поселогы.";

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта "

# "Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 42 (26) - 22 (27) | - Самара өлкәсе |
| 22 (27) - 21 (28) | - Нурлат муниципаль районы |
| 21 (28) - 2 (79) | - Аксубай муниципаль районы |
| 2 (79) - 9 (78) | - Яңа Чишмә муниципаль районы |
| 9 (78) - 31 (77) | - Әлмәт муниципаль районы |
| 31 (77) - 42 (26) | - Лениногорск муниципаль районы |

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Бәркәтә авыл җирлеге |
| 2 | Югары Кәминкә авыл җирлеге |
| 3 | Ивашкино авыл җирлеге |
| 4 | Кармыш авыл җирлеге |
| 5 | Күтәмә авыл җирлеге |
| 6 | Лашман авыл җирлеге |
| 7 | Мордва Афонькәсе авыл җирлеге |
| 8 | Түбән Кәминкә авыл җирлеге |
| 9 | Түбән Кармалка авыл җирлеге |
| 10 | Яңа Әлмәле авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Кади авыл җирлеге |
| 12 | Иске Кади авыл җирлеге |
| 13 | Иске Котыш авыл җирлеге |
| 14 | Иске Үтәмеш авыл җирлеге |
| 15 | Туймәт авыл җирлеге |
| 16 | Ульяновка авыл җирлеге |
| 17 | Чирмешән авыл җирлеге |
| 18 | Шешминка авыл җирлеге"; |

3) 9 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

**Чирмешән муниципаль районының**
**"Мордва Афонькәсе авыл җирлеге" муниципаль**
**берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Мордва Афонькәсе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Иске Үтәмеш, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш.

## Чирмешән муниципаль районының "Мордва Афонькәсе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге чиге Шешминка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мордва Афонькәсе, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мордва Афонькәсе авылының көньяк-көнбатыш почмагыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 6,3 км тарихи вал буйлап, аннары 3,6 км көньяк-көнчыгышка таба Лагерка елгасына кадәр һәм аның буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба Мордва Афонькәсе, Шешминка авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лагерка авылыннан 3,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Чирмешән муниципаль районы чиге буйлап Мордва Афонькәсе, Иске Үтәмеш авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Үтәмеш авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгыштарак урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге чиге Иске Үтәмеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мордва Афонькәсе, Иске Үтәмеш, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Чыгтай авылыннан 3,91 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 38 м "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шуннан соң әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 3,54 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 108 нче урман кварталының төньяк чигенә кадәр бара, әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап 306 м төньяк-көнчыгышка таба 103 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр, әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,66 км төньяк-көнчыгышка таба 104 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 390 м көньяк-көнчыгышка, көнчыгыш чиге буйлап 920 м төньяк-көнбатышка һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 420 м көньяк-көнчыгышка таба 105 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, әлеге урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,33 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 107 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 620 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 315 м көньяк-көнбатышка таба 111 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр бара, шуннан соң әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 60 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 990 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 113 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 195 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 415 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка, 124 м көньяк-көнбатышка һәм, сынык сызык ясап, көнчыгыш чиге буйлап 1,41 км көньяк-көнчыгышка таба 114 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 119 м төньяк-көнчыгышка, 188 м көньяк-көнчыгышка һәм 260 м төньяк-көнчыгышка таба, 0,66 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгыш чиге

буйлап көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 176 м көньяк-көнбатышка таба 117 нче урман кварталының төньяк чигенә кадәр уза, "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 0,89 км 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге чиге Чирмешән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 0,88 км төньяк-көнчыгышка таба, 146 м көньяк-көнчыгышка таба, 0,48 км кабат төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньякка таба 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 11 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Чирмешән муниципаль районының**
**"Түбән Кармалка авыл җирлеге" муниципаль**
**берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Түбән Кармалка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Кармалка авыл җирлеге Бәркәтә, Лашман, Туймәт, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Чирмешән муниципаль районының**
**"Түбән Кармалка авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Түбән Кармалка авыл җирлеге чиге Бәркәтә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бәркәтә, Түбән Кармалка, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чумач авылыннан 700 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 39, 38, 49, 57, 66, 75 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба, аннары 75, 66, 56, 47 нче урман кварталларының көнбатыш ягыннан урман ызаны буйлап төньякка таба 47 нче урман кварталының почмагына кадәр уза, анда

көнбатышка Шушма елгасына кадәр борылыш ясый һәм аның буйлап 200 м көньякка, аннары көнбатышка таба Бәркәтә, Түбән Кармалка, Туймәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бәркәтә авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Кармалка авыл җирлеге чиге Туймәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба автомобиль юлы белән озын чокыр кисешкән җиргә кадәр бара һәм автомобиль юлы буйлап 1,7 км көнбатышка таба, аннары көньякка таба озын чокырга кадәр һәм шуннан соң төньяк-көнбатышка таба Лашман, Түбән Кармалка, Туймәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Кармалка авылыннан 2,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Кармалка авыл җирлеге чиге Лашман авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,1 км көньяк-көнбатышка таба, аннары 400 м көньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң озын чокырның төньяк-көнбатыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба автомобиль юлына кадәр һәм аның буйлап 1,2 км көнбатышка таба, аннары Лашман, Түбән Кармалка, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Кармалка авыл җирлеге чиге Чирмешән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 23, 25, 26 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә озын чокырның көньяк-көнчыгыш ягына кадәр 1,3 км һәм аның буйлап төньяк-көнчыгышка таба, аннары 1,4 км төньякка таба уза, көнчыгышка таба борыла һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м басу юлына кадәр, шуннан соң юл буйлап көньякка таба Югары Чыгтай авылыннан 3,5 км төньяктарак урнашкан тарихи валга кадәр бара. Аннары тарихи вал буенча 850 м төньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,8 км төньякка таба озын чокырның төньяк ягына кадәр һәм аның буйлап 750 м көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньякка таба борыла һәм 2,3 км бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба Түбән Кармалка, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Кармалка авылыннан 3,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Кармалка авыл җирлеге чиге Шешминка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба озын чокыр уртасы буйлап, аннары инеш буйлап Шушма елгасына кадәр һәм аның буйлап төньяк-көнчыгышка таба уза, урман массивыннан 100 м узгач, төньякка таба борыла, "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталын төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп уза һәм төньяк-көнчыгышка таба 77 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 77, 67, 58, 59, 60, 61, 50, 41, 28, 40, 39 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш ягы буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

5) 12 нче кушымтаны төшереп калдырырга;

6) 17 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Чирмешән муниципаль районының "Иске Үтәмеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Иске Үтәмеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Үтәмеш авыл җирлеге Мордва Афонькәсе, Чирмешән авыл җирлекләре, Лениногорск муниципаль районы һәм Самара өлкәсе белән чиктәш.

**Чирмешән муниципаль районының "Иске Үтәмеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Иске Үтәмеш авыл җирлеге чиге Чирмешән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Үтәмеш, Чирмешән авыл җирлекләре һәм Самара өлкәсе чикләре тоташкан урында Зур Чирмешән елгасы акваториясендә урнашкан X=346662,73 һәм Y=2269704,09 координаталы 38 нче тоташу ноктасыннан алып 25 м көньяк-көнчыгышка таба, торф чыгару урыннары чиге буйлап 580 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 640 м уза, шуннан соң кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка 440 м, Чирмешән – Лениногорск автомобиль юлын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,9 км, төньяк-көнчыгышка таба 3,95 км, төньяк-көнбатышка таба 1,36 км "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 620 м әлеге урманчылыктагы 101 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап 305 м төньяк-көнчыгышка таба, 155 м төньякка таба, 126 м төньяк-көнчыгышка таба, 160 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба Мордва Афонькәсе, Иске Үтәмеш, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Чыгтай авылыннан 3,91 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Үтәмеш авыл җирлеге чиге Мордва Афонькәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

38 м "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 3,54 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 108 нче урман кварталының төньяк чигенә кадәр бара, әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап 306 м төньяк-көнчыгышка таба 103 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр, әлеге урман кварталының төньяк чиге буенча 1,66 км төньяк-көнчыгышка таба 104 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 390 м көньяк-көнчыгышка, көнчыгыш чиге буенча 920 м төньяк-көнбатышка һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 420 м көньяк-көнчыгышка таба 105 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр бара, әлеге урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,33 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 107 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 620 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 315 м көньяк-көнбатышка таба 111 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр бара, шуннан соң әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 60 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 990 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 113 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 195 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 415 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, 124 м көньяк-көнбатышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,41 км көньяк-көнчыгышка таба 114 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 119 м төньяк-көнчыгышка, 188 м көньяк-көнчыгышка һәм 260 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 0,66 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 176 м көньяк-көнбатышка таба 117 нче урман кварталының төньяк чигенә кадәр бара, "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап 0,89 км көньяк-көнчыгышка таба Мордва Афонькәсе, Иске Үтәмеш авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Үтәмеш авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгыштарак урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Үтәмеш авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып Чирмешән муниципаль районы чиге буенча Иске Үтәмеш авыл җирлеге, Лениногорск муниципаль районы, Самара өлкәсе чикләре тоташкан урында Иске Сережкино авылыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче (26 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Үтәмеш авыл җирлеге чиге Самара өлкәсе белән чиктәш җирдә 42 нче (26 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

7) 20 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм
аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Чирмешән муниципаль районының "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чирмешән авыл җирлеге Лашман, Мордва Афонькәсе, Түбән Кармалка, Яңа Әлмәле, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Ульяновка, Шешминка авыл җирлекләре, Нурлат муниципаль районы, Самара өлкәсе белән чиктәш.

**Чирмешән муниципаль районының "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Чирмешән авыл җирлеге чиге Иске Котыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Котыш, Чирмешән авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красная Поляна авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының көнбатыш ягы буйлап төньякка таба Иске Котыш, Ульяновка, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красная Поляна авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Ульяновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 56, 63, 57, 58, 51, 48, 40 нчы урман кварталларының кырые буйлап Яңа Әлмәле, Ульяновка, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Саминовка авылыннан 900 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Яңа Әлмәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 41, 35, 42, 43, 36, 37 нче урман кварталларының төньяк ягы буйлап Лашман, Яңа Әлмәле, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Әлмәле авылыннан 1,7 км көньякта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Лашман авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Лашман, Түбән Кармалка, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында

"Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км Рудник инешенә кадәр һәм аның буйлап көньяк-көнбатышка таба Кармалка инеше белән кушылганчы бара, шуннан соң "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 27, 28, 30, 32 нче урман кварталлары кырые буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба автомобиль юлына кадәр һәм аның буйлап көньякка таба "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 46 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагына кадәр, шуннан соң 46, 47, 45, 44, 38 нче урман кварталларының төньягы буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Түбән Кармалка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Казанка участок урманчылыгындагы 23, 25, 26 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә озын чокырның көньяк-көнчыгыш ягына кадәр 1,3 км һәм аның буйлап төньяк-көнчыгышка таба, аннары 1,4 км төньякка таба бара, көнчыгышка таба борыла һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м басу юлына кадәр, шуннан соң юл буйлап көньякка таба Югары Чыгтай авылыннан 3,5 км төньяктарак урнашкан тарихи валга кадәр бара. Аннары тарихи вал буйлап 850 м төньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,8 км төньякка таба озын чокырның төньяк ягына кадәр һәм аның буйлап 750 м көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньякка таба борыла һәм 2,3 км бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба Түбән Кармалка, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Кармалка авылыннан 3,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Шешминка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мордва Афонькәсе, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мордва Афонькәсе авылының көньяк-көнбатыш почмагыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып тарихи вал буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, аннары басу юлы буйлап төньякка таба 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Мордва Афонькәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мордва Афонькәсе, Иске Үтәмеш, Чирмешән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Чыгтай авылыннан 3,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 0,88 км төньяк-көнчыгышка таба, 146 м көньяк-көнчыгышка таба, 0,48 км кабат төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньякка таба 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Иске Үтәмеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Үтәмеш, Чирмешән авыл җирлекләре һәм Самара өлкәсе чикләре тоташкан урында Зур Чирмешән елгасы акваториясендә урнашкан X=346662,73 һәм Y=2269704,09 координаталы 38 нче тоташу ноктасыннан алып 25 м көньяк-көнчыгышка таба, торф чыгару урыннары чиге буйлап 580 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

640 м уза, шуннан соң кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 440 м, Чирмешән – Лениногорск автомобиль юлын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,9 км, төньяк-көнчыгышка таба 3,95 км, төньяк-көнбатышка 1,36 км "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 620 м әлеге урманчылыктагы 101 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап 305 м төньяк-көнчыгышка таба, 155 м төньякка таба, 126 м төньяк-көнчыгышка таба, 160 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Самара өлкәсе белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Чирмешән авыл җирлеге, Нурлат муниципаль районы һәм Самара өлкәсе чикләре тоташкан урында Красная Поляна авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче (27 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Чирмешән авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 22 нче (27 нче) тоташу ноктасыннан алып Чирмешән муниципаль районы чиге буйлап төньякка таба 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

8) 21 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чирмешән муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм
аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

**Чирмешән муниципаль районының**
**"Шешминка авыл җирлеге" муниципаль**
**берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Шешминка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шешминка авыл җирлеге Бәркәтә, Мордва Афонькәсе, Түбән Кармалка, Чирмешән авыл җирлекләре, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары белән чиктәш.

**Чирмешән муниципаль районының "Шешминка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Шешминка авыл җирлеге чиге Әлмәт муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бәркәтә, Шешминка авыл җирлекләре һәм Әлмәт муниципаль районы чикләре тоташкан урында Чумач авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгыштта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба Чирмешән муниципаль районы чиге буйлап Шешминка авыл җирлеге, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 31 нче (77 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Шешминка авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 31 нче (77 нче) тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Чирмешән муниципаль районы чиге буйлап Мордва Афонькәсе, Шешминка авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лагерка авылыннан 3,5 км төньяк-көнчыгыштта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шешминка авыл җирлеге чиге Мордва Афонькәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мордва Афонькәсе, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мордва Афонькәсе авылының көньяк-көнбатыш почмагыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып тарихи вал буйлап 6,3 км төньяк-көнчыгышка таба, аннары 3,6 км көньяк-көнчыгышка таба Лагерка елгасына кадәр һәм аның буенча 900 м көньяк-көнбатышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шешминка авыл җирлеге чиге Чирмешән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып тарихи вал буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, аннары басу юлы буйлап төньякка таба Түбән Кармалка, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Кармалка авылыннан 3,8 км көньяк-көнчыгыштта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шешминка авыл җирлеге чиге Түбән Кармалка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып озын чокыр уртасы буйлап төньякка таба, аннары инеш буйлап Шушма елгасына кадәр һәм аның буенча төньяк-көнчыгышка таба бара, урман массивын 100 м узгач, төньякка таба борыла, "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталын төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп уза һәм төньяк-көнчыгышка таба 77 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 77, 67, 58, 59, 60, 61, 50, 41, 28, 40, 39 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш ягы буйлап Бәркәтә, Түбән Кармалка, Шешминка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чумач авылыннан 700 м төньяк-көнчыгыштта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шешминка авыл җирлеге чиге Бәркәтә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып "Чирмешән урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шушма участок урманчылыгындагы 6, 5, 16, 27, 26, 39 нчы урман кварталлары буйлап көньяк-көнбатышка таба 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 3 июле
№ 48-ТРЗ

"Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта"

# "Чирмешән муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 42 (26) -22 (27) | - Самара өлкәсе |
| 22 (27) -21 (28) | - Нурлат муниципаль районы |
| 21 (28) -2 (79) | - Аксубай муниципаль районы |
| 2 (79) -9 (78) | - Яңа Чишмә муниципаль районы |
| 9 (78) -31 (77) | - Әлмәт муниципаль районы |
| 31 (77) -42 (26) | - Лениногорск муниципаль районы |